СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

04.02.2026 с. Верхний Услон № 5-59

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 19.01.2026 ел № 58/о боерыгы кабул ителүгә бәйле, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 ел № 33-ФЗ Федераль законга таянып, Югары Ослан муниципаль районы Советы карар итте:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 02.10.2023 елның 37-506 номерлы “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" карары;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 27.12.2021 ел № 18-236 “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының экономик үсеш, экология, табигать ресурслары һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин